культура-агарту керәшен газетасы

# Туганайлар

№24 (508)
28 декабрь

. 2002 елның 5 октябреннән бирле чыга . . яңалыкларны www.tuganaylar.ru сайтыннан һәм социаль челтәрләрдән укыгыз . 12+

# Ява карлар, оча хыял, Тыныч еллар, бәхет теләп

**Георгий ИБУШЕВ**

*Ява карлар, карлар белән*
*Ява хыял, якты уйлар.*
*Аклык булып, сафлык белән*
*Үткәнне кар күмә шулай.*

*Олы бәхет килер сыман,*
*Аклык иңгән юлларыннан.*
*Себереп ява, уйнап ява,*
*Күңел күген кагып ала.*

*Бар борчулар, үпкә-сагыш*
*Адашсын дип, бураннарда.*
*Чистарынып күңел кала,*
*Ява карлар, оча карлар.*

*Бөтереп алып, коча алар –*
*Тыныч еллар, бәхет теләп,*
*Тирә-якны җем-җем килгән*
*Энҗе бөртек белән бизәп.*



• *Зәй районыннан килгән кунаклар — Яңа ел бәйрәмендә.* Илизә Галиуллина фотосы.

***Декабрь азагында Я.Емельянов исемендәге мәдәни үзәктә Яңа ел бәйрәмен көтеп алучы, яратучы балалар өчен "Җаңа җыл урманында ни булмас...?" дигән бәйрәм уздырылды. Инде берничә ел рәттән мәдәни үзәк хезмәткәрләре, республика керәшен оешмасының "Бәрәкәт" яшьләр бүлеге кызлары-егетләре белән берлектә, нәни дусларыбызны, әнә шулай, бәйрәм белән котлый.***

Яңа ел – балаларга гына түгел, хәтта әкияткә ышану яшеннән чыккан олылар өчен дә могҗизалы, серле бер бәйрәм. Әгәр дә Яңа ел бәйрәменә 2024 ел символы булган Аҗдаһа, аны серле керәшен урманын иңләп-буйлап эзләп йөрүче мәче малае Бәчкә, тигр улы Макар һәм Кар бабай – Олаф үзе килсә, "җаңа җыл урманында ни булмас", дип, ышанмас җиреңнән ышанырсың шул. Адашкан аждаһаны эзләп йөргәндә, бар дөньяны онытып, балалар интерактив уеннар белән дә мавыгып алдылар. Керәшен урманында адашкан аждаһаның эзләренә чыкканда алар куянны, хәтта әкияттәге Красная шапочканы да очраттылар!

Әлбәттә, ел буе көтеп алган Кыш бабай белән Кар кызын да дәште балалар.

Балалар да, олылар да, әкият геройлары да – барыбыз бергә эзли торгач, Яңа ел символы табылды. Анысы табылды табылуын, тик чыршының иң затлы бизәге – йолдызы юкка чыкты. Ә анысын да эзләп тапкач, уртак шатлыктан, рәхәтләнеп, дискәтүктә күңел ачтылар. Бәйрәмдә, бәләкәй кунаклар керәшен биюләрен дә биеделәр, җырладылар да, Кыш бабайга әзерләп килгән шигырьләрен дә сөйләделәр.

Әлеге Яңа ел тамашасына башкалабыздан гына түгел, төрле районнардан да балалар килгән иде. Зәй районыннан махсус хәрби операциядәге карендәшләребезнең биш баласы да катнашты.

– Әтиләре махсус хәрби операция зонасында булган балаларны алып килдек. Кайберләре – әниләре, кайберләре – әби-бабасы белән. Районнан автобус бирделәр, зур рәхмәт! Балаларның шатлыклы йөзләрен күрүгә ни җитә?! – дип әйтте Зәй керәшен җәмгыяте председателе, балалар өчен сөенече йөзенә чыккан Валентин Атласов.

Бәйрәм азагында балалар мастер-класста имбирьле прәннекне тәмле глазурь белән бизәделәр. Озаклап сокланып тормадылар, шул тәмнүшкәләр белән рәхәтләнеп чәйләп тә алдылар.

Кызлар һәм малалайлар! Киләсе 2024 ел азагында да Җәкәү йортындагы Яңа ел бәйрәменә тагын да зуррак үсеп, матур-матур шигырьләр ятлап, җырлар өйрәнеп килегез.

Ак карларга уралып, куанычлы һәм имин еллар килсен җир йөзенә! Һәркем бәхетле, исән-сау булсын!

## Яңа ел һәм Рождество бәйрәмнәре белән!



Хөрмәтле карендәшләр һәм газета укучылар!

Тагын бер елыбыз үтеп бара. Бу 2023 ел да җиңел еллардан булмады. Илебез, республикабыз халкы катлаулы авыр шартларда бердәмлек, ныклык күрсәтеп, Россияне икътисад һәм социаль яктан алга киткән ил итү өчен тырыша. Ватан кушкан бурычны үтәп, ир-егетләребез махсус хәрби операциядә батырлык үрнәкләре күрсәтә. Тынычлык хакына һәркем үз тармагында намус белән эшли.

Татарстанда – милли мәдәниятләр һәм традицияләр, ә Россиядә укытучы һәм остаз елы булган 2023 елда үсеп килүче яшь буында туган җирне ярату, патриотлык хисләре тәрбияләүгә зур урын бирелде. Патриотлык әле ул үз халкыңны, йола-гадәтләренне, традицияләрне дә белү, ихтирам итү һәм үтәү. Республика керәшен иҗтимагый оешмасы, культура хезмәткәрләре, тәрбиячеләр, укытучылар бу эшкә үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр. Республикакүләм "Туым жондозы" һәм "Питрау" фестивальләрен, конкурслар һәм милли бәйрәмнәрне керәшен кунакчыллыгы белән зурлап үткәрүебез дә шуны раслый.

"Туганайлар" газетасын укучыларны Яңа 2024 ел һәм Рождество белән чын күңелдән котлыйм. Яңа ел Ватаныбызга иминлек, дөньяларга тынычлык, һәркемгә ныклы саламәтлек алып килсен. Һәрвакыт бергә һәм бердәм булыйк, карендәшләр!

**Иван ЕГОРОВ,**
Татарстан республикасы керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы җитәкчесе.

## Бүгенге санда:

**ИЛНУР ӘХӘТОВ: "БӘРМӘНЧЕК"ТӘ БУЙГА ТҮГЕЛ, СӘЛӘТКӘ КАРЫЙЛАР**

"Кряшен чибяре" конкурсын да алып баручы татар егете керәшеннәр турында нәрсәләр сөйли?

4нче бит

**ЯНТАРЬ ТАШЛЫ, БАЛТЫЙК ДИҢГЕЗЛЕ КАЛИНИНГРАД**

Газетабыз журналистын серле хомлин-сынлы урамнар, "котошеф" һөнәрле Зеленоградск шәһәре, "Куршск толымы" таң калдырган

5нче бит

**"МИН — БӘХЕТЛЕ, ХЫЯЛЛАРЫМ ЧЫНГА АША"**

Зәй егете Андрей Кузьмин камил булмаган куллары белән искиткеч матур картиналар ясый

7нче бит

**ДӨНЬЯГА ЧЫНЛЫК КОЯШЫ КИЛДЕ**

Кешелек дөньясының Коткаручысы Иисус Христос тугач, янына килгән җондозчылар аңа алтын, ладан, смирна бүләк итәләр

10нчы бит

# Керәшенчә марафон

*1-21 март көннәрендә ВКонтакте социаль челтәрендә "Керәшенчә марафон" гөрләде. Аңа республикабызның төрле районыннан 40 карендәшебез кушылды*

***Марафончылар, көн саен аерым бер тема кысаларында, үзләре, нәселләре белән таныштырды, йөрәк түрләрендә булган иң кадерле истәлекләре белән уртаклаштылар. Гаилә мирасы, аш-су, балаларга керәшен тәрбиясе бирү, язучыларыбыз, артистларыбыз турында һәм дин, фольклор буенча мәгълүм постлар урнаштырдылар. Язып кына түгел, матур фотолар, видеолар да куйдылар.***

***ВКонтактеда #керәшенчәмарафон #туганайлармарафоны дигән хештеглар аша кереп укысагыз, гаҗәеп уңган, булган карендәшләребез һәм аларның язмалары белән таныша аласыз.***

***Керәшенчә марафонга нәтиҗәне газетабызның киләсе саннарында ясарбыз. Бу юлы исә, марафон вакытында язылган берничә кызыклы һәм мәгълүм язманы тәкъдим итәбез.***

## 3нче көн: Гаиләм мирасы



**Лариса ӘХМӘТШИНА,** *Минзәлә районының Мәлкән авылы:*

– Гаиләм мирасы дигәндә, иң башта, гаиләмдә саклана торган кадерле истәлекләрне барлыйм. Әниемнең әнисе – бәбүтәдән калган керәшен әлифбасында басылган иман китабы – үз-үзеңне тоту кагыйдәләре җыелмасы. Бу – 4 класслы Мәлкән чиркәү мәктәбен тәмамлаган, чиркәү хорында җырлаган, гомере буе үз диненә тугры булган иман иясе әбиебезнең кадерле мирасы.

Әниемнең кыска гына гомере эчендә үз куллары белән чиккән әйберләре – пар күгәрченле бистәре, миңа бирнәлек итеп әзерләгән пар мендәр тышы, йөзләгән кульяулыкларының берсе әле дә саклана миндә. Шулай ук, болында чәчәк җыеп йөргән пар кызлар чигелгән бистәрне дә әтиемнең апасы – Татук түтинең истәлеге итеп кадерләп саклыйм. Күз алдымда – һәр көнне, аз гына буш вакытлары булдымы (кичләрен инде әйтәсе дә юк!), каба артында, яки бәйләм бәйләгән бәбүтә белән чигү чигеп утырган мама... Өебезнең стеналарындагы "чигү"ләр, чигүле җәймәләр җәелгән диван-караватлар, мендәрләр... Без бит-кулларны да гел чигүле бистәрләргә генә сөртеп үстек, мунчадан да чигүле бистәргә сөртенеп чыктык, борын сөртер өчен дә кесәдә гел чигүле кульяулык йөрде. Ничек житештеләр икән безнең мамалар моның барысына да?! Кул белән кер юган заманнарда аларны ничек шулай ап-ап итеп юып, аклыгын озак елларга җитәрлек итеп саклый алдылар икән?!



## 7нче көн: Керәшен әдәбе



**Алёна НИЗАМОВА,** *Казан шәһәре:*

– Бездә кеше белән исәнләшми торган кеше – "әллә кем булган" кеше. Урамнан узып киткән теләсә кем белән исәнләшәләр безнең авылда. Буш өйгә кергәндә дә Җорт иясе белән исәнләшәләр. Керәшеннәрнең ачык булулары шуннан башланадыр да. Керәшеннәр "әллә кем"нәр булып кыланып тормый, чөнки бөтен кеше бер төсле туа, зыяратта да бер рәттә ята.

Балаларга өйрәтә торган әдәпнең тагын берсе: Аллага шөкер, Алла боерса дип әйтә белү. Идәнгә ризык төшерергә ярамый; идәнне ишек катыннан эчкә таба юа башларга, себерергә ярамый; өстәлгә ашъяулык капланган булырга тиеш. Олыларга каршы да, әшәке сүз әйтергә дә, беркемне алдаларга да ярамый. Бурлык – иң олы хурлык. Кергән кунакны чәй эчертмичә чыгармыйлар. Кояш баеганда йокларга ятмыйлар – җеннәр чыккан чак. Кешегә зыянның килергә тиеш түгел, Ходай күреп тора. Питраууга хәтле үсемлекләрне өзәргә ярамаган – Питраудан соң гына бар нәрсә дә җитешкән, өлгергән – Җир-анага зыян китермәгәннәр, җиләк ашамаганнар. "Кош оя итмәс" көнне яңа эш башларга ярамый, җир җаралган көнне җиргә сугарга да, пычрак су түгәргә дә ярамый – керәшеннәрдә табигать белән якын булу каннан килә. Бик күп ул андый "ярамый"лар, гомер узган саен шулар искә төшә дә, онытыла. Әбиләр сүзе хәзерге психологлардан да көчлерәк булган, дип нәтиҗә ясадым. Мәсәлән, ачу чыкса, табигатькә чыгып җилләргә, өй җыештырырга кушалар. Баштан яулык төшмәскә, чәч җыелган булырга тиеш, ашарга пешергәндә алъяпкычың булсын.

Эшең бармаса, зур юлга чыгасы булсаң, мескенгә яки хайванга хәер бирергә. Җан тынычлыгы китсә, баланың башыннан сыпырырга, карт кешенең хәлен белергә... һәм башкалар.

## 6нчы көн: Бер фотосурәт тарихы



**Любовь ПАВЛОВА,** *Кукмара районының Үрәсбаш авылы:*

– Күңелемә аеруча якын, кадерле булган бу фото 1969 елда төшерелгән. Анда – әнием (әбием) һәм өч яшьлек нәни кыз бала – мин. Әнием вафатыннан соң, мин ятим калам. Шулай булса да, миңа ятимлек ачысын татырга туры килмәде. Шушы олы йөрәкле ана, әбием – мине үз канаты астына алып, җил-яңгыр тидермичә үстерде. Минем борчуларымны, шатлыкларымны эченә сыйдырган газиз әнием ул! Аның янәшәмдә булуы аркасында миңа ятимнәр йортының ишеген шакырга туры килмәде. Бик кадерле бала булып, тулы гаиләдә үстем. Әнием (әбием) белән әтием мине тәрбияләүгә бик зур көч куйдылар. Әле дә хәтеремдә – мәктәптә укый башлагач, әнием ата-аналар җыелышына бер сәгать алдан бара, "И-и, кызым, сине мактадылар" – дип, сөенеп кайта иде.

Әнием, әбием! Кызганыч, бүген мин әлеге сүзләрне беркемгә дә әйтә алмыйм. Газиз кешемнең вафатына да 24 ел вакыт узды. Сандык төбендә сакланган киемнәренә, стенадагы фотосурәтенә күз төшергән саен, аның белән яшәгән еллар күз алдыма килә. Нәрсәгә тотынсам да, әниемнең эзен күрәм. Фотосурәттәге әбисенә елышып утырган кыз, инде үсеп җитеп, үзе тормыш алып барса да, сине сагына, юксына. Кадерлемнең иркәләп: "Кызым", – дип әйткән сүзләре колакта чыңлап тора. Әнием һәрчак: "Бәхетең генә булсын инде, балам", – дип әйтә иде. Шөкер, мин тормышта үз юлымны таптым, гаиләле, һөнәрле булдым. 35 ел шул яраткан һөнәремә тугрылыклы булып хезмәт итәм.



Менә нинди хисләрне кабызның син, әниемне алыштырган газиз әбием!

## 14нче көн: Милли кием



**Лариса КИБЯКОВА,** *Балык Бистәсе районының Кызыл-Йолдыз лесхозы авылы:*

– Керәшен фольклор коллективы оештыра башлагач, иң беренче проблема милли киемнәр табу булды. Әнием белән икәүләп авылны йөреп чыктык. Кемдер – керәшен күлмәге, кемдер – алъяпкыч, кемдер – муенҗакасын, ә Роза Сергеевна Елесеева 2 чулпы бирде. Сөенүемне күрсәгез!.. Шушы элекке иске киемнәрне киеп фестивальдә катнаштык. Анда баргач шаккатым, барысында да диярлек, яңа теккән киемнәр. Бездәге кебек муенҗака белән чулпылар берсендә дә юк. Борынымны сузып кайттым инде, бездә генә иске киемнәр икән дип.

Шуннан эзләнә торгач Түбән Камадан Тамара Баһаветдинова үз ансамбльләренең иске күлмәкләрен бирде. Яшел төсле яңа фасон күлмәкләр. Аларга төс итеп, кара чалбарлар сүтеп, әни белән камзуллар тектек. Шуннан соң, лесхоз директоры Камил Газизов яңа фасондагы шакмаклы материалдан керәшен күлмәкләре тектереп бирде. Менә ул бәхет!.. Кая барсак та күлмәкләр бар хәзер!

Бик күп фестивальләрдә катнашып йөри торгач кына аңладым, ә бит иң кыйммәтле күлмәк хәзерге яңа тегелгәннәре түгел, ә әбиләребездән калган иске этник, чын керәшен күлмәкләре икән! Хәзер без аларны горурланып киябез. Милли бәйрәмнәрдә дә бит чын керәшен күлмәге кигән кешегә борылып, сокланып карыйлар, ә кыйммәтле кибет күлмәге кигән кешегә түгел.

*Милли киемнәрне бик кадерләү,*
*Канга сеңгән безгә тумыштан;*
*Күлмәк,алъяпкычлар – киндер булса,*
*Муенҗака, беләзек – көмештән.*

*Бик яратып киям бәйрәмнәрдә,*
*Искә алып җырак әбине.*
*Керәшенчә итеп тәрбиялим,*
*Бишектәге оныкбәбине.*



## 11нче көн: Керәшенлек



**Лидия ПАСЫЕВА,** *Мамадыш районының Усали авылы:*

– Үзеңне керәшен дип санасаң:

1. Әти-әниең, әби-бабаңнарның керәшен икәнен бел. Булдыра алганча нәсел агачыңны төзе.
2. Керәшен халкының тарихын өйрән. Тәнкыйть күзлегеннән карарга тиешле тарихлар да бар. Игътибарлы бул!
3. Православие нигезләрен өйрән. Чиркәүгә бар. Керәшеннәрдәге дин китапларын өйрәнсәң, тагын да әйбәт!
4. "И, күктәге Атабыз" ("Отче наш") иманын һәр керәшен яттан белергә тиеш.
5. Керәшенчә язу бар икәнен бел. Дин китапларыбыз шул язу белән язылган.
6. Православие динен тот, башкаларныкын хөрмәт ит.
7. Дин алыштыруның зур язык (гөнаһ) икәнен белеп тор.
8. "Ризыктан олы булма!"– дип өйрәтә керәшеннәр. Ләкин ураза көннәрен һәм аның таләпләрен бел.
9. Ураза тот. Булдыра алмасаң, тотучыларны хөрмәт ит.
10. Керәшен киемнәрен өйрән. Аларны башка халыкныкылардан аера бел.
11. Керәшеннәрнең асыл затларын: агартучыларын, изгеләрен, геройларын, галимнәрен, спортчыларын, иҗат кешеләрен – артистларын, язучы-шагыйрьләрен, галимнәрен, художникларын бел.
12. Булдыра алсаң, нәсел тамгаларыбызны өйрән.
13. Тәре (икона) белән качны (крест) бутама. Керәшен кешесенә моны белмәү ярамый да, килешми дә!
14. "Православие динендәгеләргә алкоголь кулланырга ярый", – дисәләр, ышанма. Дөрес түгел! Аны безнең дин дә тыя.
15. Үзеңне кимсетергә ирек бирмә! Ә моның өчен керәшен булуың белән горурланырга, халкың, тарихың турында күп белергә кирәк.
16. Халкыбыз өчен чыга торган "Туганайлар" газетасына языл. Анда динебез, культурабыз, күренекле кешеләребез турында укырга, теләгең булса, үзенә дә язарга була.
17. Белгәннәреңне, керәшенлегеңне киләчәк буынга тапшыруны бурычың итеп сана.

*Керәшенчә марафон кысаларында әзерләнгән язмаларны бирүне алга таба да дәвам итәрбез, чөнки барлык карендәшләргә дә ишеттерерлек бик тә төпле һәм үткен фикерләр яздылар марафончылар.*

Язманы **Юлия ГУБИНА** әзерләде.

pdfpiska.ru